ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 18 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 1 өлешендә:
а) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3) психик тайпылышлары булган гражданнар, шул исәптән психик тайпылышлары булган балалар өчен интернат йорт;»;
б) 4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 8 статьяда:
а) 1 өлештә:
1 пунктка түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасы өстәргә:
«е) социаль хезмәтләр күрсәтүләрдән файдаланучының бозылган функцияләрен коррекцияләү өчен билгеләнгән приборлардан файдалануда ярдәм күрсәтү;»;
5 пунктка түбәндәге эчтәлекле «д» – «ж» пунктчалары өстәргә:
«д) хәрәкәт иткәндә (күчеп йөргәндә) ярдәм күрсәтү;
е) кер юу һәм үтүкләү;
ж) кием (эчке киемнәр) һәм урын-җир алыштыру.»;
б) 2 өлештә:
1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) социаль хезмәт күрсәтүнең бөтен рәвешләрендә – социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларны сәламәтлекләре торышындагы тайпылышларны ачыклау максатларында системалы рәвештә күзәтеп тору;»;

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле «д» – «з» пунктчалары өстәргә:

«д) социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның сәламәтлеген күзәтеп торуга бәйле процедураларны үтәү;

е) табиб билгеләве буенча медицина процедуралары үткәрү;

ж) савыктыру чаралары үткәрү;

з) социаль-медицина мәсьәләләре буенча консультацияләр бирү.»;

в) 3 өлешнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) өйгә барып социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә һәм социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә – социаль-психологик патронаж.»;

г) 4 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3) өйгә барып социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә – өлкән яшьтәге гражданнарны һәм (яки) инвалидларны караучы гражданнар арасыннан булган социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларга өлкән яшьтәге гражданның һәм (яисә) инвалидның торак урынын җайлаштыру мәсьәләсе буенча консультацияләр бирү.»;

д) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Яшәеш мөмкинлекләре чикле булган социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның коммуникатив потенциалын арттыру максатларында Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт күрсәтүләргә түбәндәгеләр керә:

1) социаль хезмәт күрсәтүнең бөтен рәвешләрендә – социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль-реабилитация чаралары үткәрү;

2) социаль хезмәт күрсәтүнең стационар һәм ярымстационар рәвешләрендә:

а) инвалидларны (инвалид балаларны) үз-үзләрен карау чараларыннан һәм техник реабилитация чараларыннан файдалануга өйрәтү;

б) үз-үзенә хезмәт күрсәтү, көнкүрештә һәм җәмәгать урыннарында үз-үзен тоту күнекмәләренә өйрәтү.»;

е) 8 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) психик тайпылышлары булган гражданнар, шул исәптән психик тайпылышлары булган балалар өчен интернат йортларда социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендәге социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларны медицина оешмаларына госпитализацияләгәндә (психиатрия ярдәме һәм «фтизиатрия» юнәлеше буенча медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларыннан тыш) әлеге файдаланучыларны карауны гамәлгә ашыру максатларында озатып йөрү.»;

3) 11 статьяның 4 өлешендә «социаль хезмәт күрсәтү елыннан алда килгән елның икенче кварталы йомгаклары буенча» сүзләрен «тиешле елга» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пункты 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты                           Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 08 апрель
№ 19-ТРЗ